ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**27.10.2022ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2968**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чаралары турында

Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары буенча, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә, хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә өстәмә ярдәм билгеләү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарының гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге ярдәм чараларын билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында 1-11 сыйныф укучылары арасыннан гаилә әгъзаларына бушлай ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) бирү;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында балаларын караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләреннән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. Ярдәм чаралары ата-ананың (законлы вәкилнең) белем бирү учреждениесе җитәкчесе исеменә язма гаризасы, хәрби комиссариат белешмәсе, бала туу турында таныклык нигезендә бирелә.

3. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган ассигнованиеләр

чикләрендә гомуми белем бирү оешмалары укучылары өчен уку вакытында тукланыуны оештыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны гамәлгә ашырырга.

4. Әлеге карарның 1 пунктында каралган ярдәм чарасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә өлешчә мобилизация буенча гражданның хәрби хезмәт узу чорында гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин